**Обращение Президента Республики Татарстан Р.Н. Минниханова по случаю празднования Дня родного языка и 135-летия со дня рождения Габдуллы Тукая**

*26.04.2021*

Дорогие татарстанцы!

Уважаемые соотечественники!

Сердечно поздравляю вас с Днём родного языка и 135-летием со дня рождения великого татарского поэта Габдуллы Тукая.

Для татар всего мира его живая, образная поэзия всегда была и остаётся незыблемым нравственным ориентиром, эталоном чистоты и выразительности родного языка, одним из фундаментальных начал, на которых основывается наша национальная идентичность. Как замечательно сказал известный татарский поэт Ильдар Юзеев: «Народу ясно светишь ты в искусстве Солнцем и Луной, / Тебя, бесценный наш Тукай, чтит мир и чтит народ родной»!

Короткая, но полная одухотворяющего творческого огня жизнь поэта пронеслась по широкому небосводу истории татарского народа, великой России и огромного тюркского мира яркой, стремительной кометой, осветив собой всю нашу многовековую национальную культуру. В Тукае гармонично уживались и ранимый лирик, и бескомпромиссный публицист, и вдумчивый философ, и тонкий сатирик, и непререкаемый борец за свободу и счастье своего народа. Недаром и по сей день его гениальная поэзия даёт ответы на многие актуальные вопросы современности.

С помощью высокого художественного слова Тукай сумел донести до нас вечные духовные истины, объединяющие представителей различных национальностей и вероисповеданий, открыл для России и всего мира неисчерпаемые богатства татарского языка, тайны наших древних преданий, уникальную красоту обычаев и обрядов. Особое значение празднование его дня рождения, отмечаемого в Татарстане как День родного языка, приобретает в Год родных языков и народного единства, призванного в ещё большей мере сплотить всех нас на принципах любви к «святому языку отца и матери», взаимоуважения и сопричастности к выдающимся историческим свершениям.

Беречь и приумножать родной язык, создавать необходимые условия для его изучения и популяризации, сеять с помощью живого слова «разумное, доброе, вечное» – приоритетная задача каждого из нас, творческой интеллигенции, общества и государства. В Татарстане многое делается в этом отношении, и мы намерены и впредь следовать проторенной Тукаем и нашими выдающимися просветителями дорогой к миру и процветанию.

Дорогие друзья! Пусть День родного языка станет для всех нас праздником духовности и красоты родной речи! От всего сердца желаю вам крепкого здоровья, счастья и благополучия!

С праздником!

Президент Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Туган тел көнен һәм Габдулла Тукайның тууына 135 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ**

*26.04.2021*

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле милләттәшләр!

Сезне Туган тел көне һәм бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 135 ел тулу уңаеннан чын күңелдән тәбрик итәм!

Дөнья буйлап сибелеп яшәүче татарлар өчен аның гаҗәеп тасвирлы, җанлы шигърияте һәрчак әхлакый маяк, туган телнең сафлыгын һәм тәэсир көчен күрсәтүче гүзәл үрнәк, милли тәңгәллегебезгә бәрәкәтле җирлек булып тора. Күренекле татар шагыйре Илдар Юзеев сүзләре белән әйтсәк: «Сәнгатебез күкләрендә — Кояшыбыз, Аебыз, / Бар җиһанга күренерлек кадерле Тукаебыз!»

Татар халкы, бөек Россия һәм чиксез төрки дөнья тарихы күгендә якты эз сызып атылган йолдыздай, шагыйрь кыска гына гомерен илһамлы иҗатта уздырды, күпгасырлык милли мәдәниятебезгә яңа төсмерләр, балкыш өстәде. Тукай – гаять сизгер, нечкә лирик та, шул ук вакытта үз юлыннан тайпылмаган туры сүзле публицист та, төпле фикер иясе, үткен сатира остасы да, үз халкының бәхетен һәм азатлыгын даулаучы көрәшче дә. Аның даһиларча тоемлау белән язылган әсәрләрендә безнең заманда да әһәмиятен югалтмаган бик күп сорауларга җавап табарга мөмкин.

Галиҗәнап сүз аша, шигъри тел белән Тукай безгә төрле милләт һәм дин вәкилләрен берләштерә торган мәңгелек рухи хакыйкатьләрне, Россия, бөтен җиһан алдында татар теленең байлыгын, борынгы әкият-риваятьләребезнең тирән мәгънәсен, гореф-гадәтләребез, йолаларыбызның кабатланмас ямен ачып бирде. Шагыйрь дөньяга килгән көн Татарстанда Туган тел көне буларак билгеләп үтелә. Үзара хөрмәт һәм олы тарихи вакыйгаларда катнашу аша безнең тагын да ныграк туплануыбызга этәргеч биргән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында бу бәйрәм аеруча зур әһәмият ала.

Туган телебезне саклау һәм үстерү, аны өйрәнү һәм популярлаштыру өчен шартлар тудыру, сүз ярдәме белән акыл, шәфкать, гыйлем орлыкларын чәчү – иҗат интеллигенциясенең дә, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең дә, гомумән, һәрберебезнең дә изге бурычы. Татарстанда бу юнәлештә күп эшләр башкарыла һәм без киләчәктә дә Тукаебыз һәм башка мәшһүр мәгърифәтчеләребез күрсәткән тынычлык, үсеш, алгарыш юлыннан баруыбызны дәвам итәчәкбез.

Кадерле дуслар! Туган тел көне һәммәбез өчен көйле-җырлы телебезнең матурлыгы һәм рухилык тантанасына әверелсен! Ихлас йөрәктән сезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!

Бәйрәм мөбарәк булсын!

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

# Язлар бүләк итте Тукайны.

Зәңгәр күк йөзендә кояш балкыган чакта, шаулап-гөрләп яз ае, апрель килгәндә, моннан 135 ел элек, 1886 нчы елның 26 апрелендә нәни –Апуш – Габдулла – мәшһүр Тукай дөньяга килә.

Тукай үзенең кыска гомеренең һәр минутын халыкка багышлаган, балаларны яраткан һәм үзенең әсәрләрендә балаларны хезмәтне яратырга өйрәткән, зурларны хөрмәт итәргә өндәгән, татар телебезнең гүзәллегенә дан җырлаган.

Илебезнең төрле төбәкләрендә бу көнне олуг шагыйребезне зур хөрмәт бедән искә алалар. Безнең 18 нче “Кыңгырау”балалар бакчасында да «Сандугачтай моңлы Тукай теле» бәйрәме узды.

Максатыбыз - балаларны Г.Тукайның тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру, шагыйрьнең иҗатына мәхәббәт, кызыксыну уяту. Тукай әсәрләре ярдәмендә мәрхәмәтле, гадел, намуслы, әхлаклы балалар тәрбияләү.

Бәйрәмдә өлкәннәр һәм мәктәпкәчә әзерлек төркеменә йөрүче балалар катнашты.

Әзерлек алдан ук башланды. Балаларны презентацияләр, фильмнар аша шагыйрьнең тормышы; экиятләр, мультфильмнар ярдәмендә иҗаты белән таныштырдык.

Бәйрәмдә балалар шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар, Тукай әкиятләре дөньясына виртуаль онлайн сәяхәт ясадылар. Балалар оркестры “Туган тел”не башкарды.

Шүрәле, Су анасының бәйрәмгә килүе балалар өчен бик күңелле булды. Алар Тукай әкиятләрендәгечә балаларны тәрбияле, акыллы булырга өндәделәр, бергәләп уеннар уйнадылар.

Бәйрәмне татар халкының гимнына әверелгән“Туган тел”ен җырлап тәмамладык.

Апрель аенда туган Тукай абый,  
Яратабыз шуңа бу айны.  
Онытырга безнең хакыбыз юк-  
Онытмабыз мәңге Тукайны!